# Терлекчелек - көнүзәк өлкә

# СЫЕРНЫҢ СӨТЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ДУҢГЫЗНЫҢ ДА ИТЕ - ТЕЛЕНДӘ

***Дуңгызлар симерту буенча автомат - комплекс 1978 елдан бирле эшли. Аның маллар саны 10,5 меңгә, өч циклга үрчем алу 28 меңгә, тәүлеклек артым алу 500 граммга җиткән үсеш еллары да, малларның ни баш саны, ни үрчем, ни артым белән мактана алмаган чигенеш елы да булган. 1997 елга комплекс шулай ук бик мактанырлык хәлдә аяк басмады. 1 гыйнварга биредә 3720 баш терлек исәпләнә, тәүлеклек артым декабрьдә 306 грамм тәшкил итә иде. Икенче төрле әйткәндә, комплекстагы 10 линиянең 4се бөтенләй буш иде. Финанс белән дә хәл мөшкел: комплекс катнаш азык өчен элеваторга 1 миллиардка якын әҗәтле булды, хуҗалыкларга бурычы 730 миллион сумга җитте (дөрес, 324 миллион сум тегеләре дә тиеш иде ...).***

***Яңа елга комплекс шулай аяк басты. Әмма елның беренче көннәреннән ук биредә үзгәрешләр рухы өерелеп килеп керде. Ул нәрсәдән гыйбарәт соң? Шулар хакында без автомат - комплекс директоры К.С.ФӘЙЗУЛЛИН белән сөйләшәбез.***

- Безнең бу нияткә нинди «мирас» белән алынуыбызны үзегез үк санап үттегез. Биредә безнең гаеп тә булгандыр һәм гомумән районда дуңгызчылык тармагына игътибар җитеп бетмәү дә үзен сиздергәндер. Район хакимиятендә моңа караш тамырдан үзгәрү безне ныклап уйланырга мәҗбүр итте. Бездәге үзгәреш - Синдряков исемендәге, «1 нче май», «Рассвет», Якты Күл КХАларын, автомат - комплексны Норлат - Октябрь ит комбинаты белән берләштерүдән килеп чыга. Бу берләштерү терлек азыгы җитештерүдән башлап ит җитештерү, аны эшкәртү, реализацияләүне файдалы, табышлы итеп башкаруны максат итә. Мондый берлектә һәркем - азык әзерләүче дә, ит җитештерүче дә уртак максатка, ахыр нәтиҗәгә эшли, шунлыктан ул җитештерүнең аз чыгымлы, табышлы булуы өчен кызыксынган була. Без - шул агрофирмада бер мөһим җитештерүчеләр звеносыннан, шуңа да үзгәрешләр иң әүвәл бездән башланып дөрес эшләнә дип уйлыйбыз. Быел җәйгә безгә дуңгызларның баш санын 10 меңгә җиткерү бурыч ителә. Хәзер әле ул 4460 баш кына булса да, без моны реаль нәрсә дип саныйбыз. Иң әүвәл, әлеге малларны асрау һәм ашату шартларын булдырырга кирәк. Шунлыктан хәзер бездә буш торган 4 линияне ремонтлау, тәртипкә салу эшләре башланды. Су белән тәэмин итү начар иде, аны шулай ук төзәтәбез. Әмма иң мөһиме - 10 еллап тик торган катнаш азык заводы эшли башлады. Аның яңа начальнигы Фомин Александр заводны торгызуда, аны эшләтүдә зур көч куйды. Хәзер штат тупланган, читтән арзан бәягә сатып алынган бөртектән иң гади рецепт белән (кукуруз, бодай, арпа, май калдыклары, сөяк оны, тоз һәм башкалар) катнаш азык җитештерелә башлады.

**- Бу сезнең өчен шулкадәр мөһимме?**

- Әлбәттә! Катнаш азык дуңгызлар өчен төп туклыклы азык бит. Аңа тәүлеккә ике тонна аертылган сөт, патока, ит комбинатында дефицит саналмаган сөяк - ит оны, май өстәп малларга тулы канлы рацион булдырырга тырышабыз. Майга килсәк, шунысын да әйтергә кирәк: гыйнвардан 60ар баш исәбеннән 3 контроль группасы оештырдык. Аларның беренчесенә майны 30 грамм, икенче группаларга 50шәр, өченчеләренә 100әр грамм исәбеннән бирәбез. 10 көннән соң үткәрелгән үлчәү түбәндәгене күрсәтте:

I группада маллар 105 грамм, II группада 175, өченчесендә 289 грамм өстәмә артым биргән. Шулай итеп, гыйнварда комплекс буенча тәүлеклек үсеш 408 грамм, ә С.Маськин һәм Ә.Минзарипова группасында 437 граммга җитте. Димәк, сыерның сөте генә түгел, дуңгызның ите дә телендә икән!

**- Бу җәһәттән хезмәтне оештыруда үзгәрешләр шулай ук каралгандыр.**

- Ансыз булмый, әлбәттә. Аның төп асылы дуңгыз караучыларның хезмәткә мөнәсәбәтен тамырдан үзгәртүдән гыйбарәт иде. Аларның аңына бер нәрсәне сеңдерергә тырыштык: хезмәткә түләү - ахыр нәтиҗәдән: күпме азрак сарыф итеп күбрәк җитештерсәк - шулкадәр үзебезгә дә отышлырак. Моның өчен исәп - хисап ясауның чек системасы кертелде. Дуңгыз караучылар бер цехны хасыйл иттеләр, цех начальнигы Александр Катков һәр хезмәт күрсәтүче (тракторчы, шофер) белән чек аша исәпләшә башлады. Сүз уңаеннан, А.Катков биредә комплекс ачылганнан бирле эшли, аңа үз бурычларын искәртеп торасы юк. Киләчәктә бу ысулны камилләштереп, һәр чыгымга контрольне көчәйтү хәстәрен күрәчәкбез. Анда электр энергиясенә аерым учет шулай ук каралган. Әлегә безнең тулы комплекска бер счетчик булса, киләчәктә аны һәр линиягә, котельнягa, һәр цехка аерым куярга исәплибез. Бу безгә продукциянең үзкыйммәтен киметергә булышачак. Эшчеләр исә аның беренче нәтиҗәсен хезмәт хакында тоюга үзләре үк кызыксынырлар дип ышанабыз.

**- Камил Сөләйманович, бу сезнең поставщиклар белән мөнәсәбәткә дә яңалык өстәячәкме?**

- Бүген комплекста малларның баш санын арттыру максат ителә икән, шунсыз булмаячак, әлбәттә. Элек без поставщикларыбыз белән тыгыз элемтәдә тордык дип мактана алмыйбыз. Аны шул да күрсәтә: 1996 ел башында безнең 22 поставщигыбыз булса, ел ахырына алар 16ау гына калдылар. Былтыр без хуҗалыкларга 584 баш ремонт дуңгызлары тараттык. Кызганычка каршы, алардан бер генә өстәмә дә ала алмадык. Ә бит районда 25 хуҗалык дуңгызчылык белән шөгыльләнә. Нигездә безнең иң ышанычлы партнерларыбыз Кузнецов исемендәге, «40 лет Победы», Хафизов исемендәге, «Родина» КХАлары иделәр. Быел гыйнвар аеннан хуҗалыкларга тагын 360 баш ремонт дуңгызлары тараттык, бусы да фидиягә булыр дип уйламыйбыз инде. Хуҗалык - комплекс арасындагы мөнәсәбәтләрнең барлык нюансларына да тукталмыйча, шуны гына әйтә алам: элек без алардан малларны тиешле 40 килограммга җиткермичә 25 - 30 килограммлы, аны коры азыкка күчерелмәгән хәлдә үк алырга күндергән идек инде. Шул сәбәптән без аларны 40 көн буе аерым рационда, кулдан коры азык ашарга өйрәтергә мәҗбүр идек. Быел да малларның көрлегенә шундый таләп булачак. Инде алар безнең шартларга кыенлыксыз күнсен өчен быел 1500 башка исәпләнгән карантин бүлеген яңадан эшләтә башлаячакбыз. Үзебездә алынган үрчемне 20 - 25 килограмм көрлеккә җиткәч, әлеге биналарга урнаштырып, тиешле авырлыгын җыйгач, симертүгә куярга җыенабыз. Малларны комплекска илтү мәшәкатеннән коткардык инде аларны, үз транспортыбыз белән барып алабыз, зоовет-белгечебез үзе урынга барып малларны карап ала.

**- Кәефегездән күренә, эшкә теләк белән алынгансыз...**

- Аның белән район хакимияте, иң әүвәл район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин үзе кызыксынган булуы безгә зур мораль ярдәм, матди терәк бирә. Бу мәсьәләдә безгә хакимият башлыгы урынбасары Ю.В.Терентьев булышлык күрсәтә, берләштерелгән хуҗалык җитәкчесе С.И.Белогубов белән киңәшеп эшләү дә файдага. Бүгеннән эшне һәрьяклап уйларга тырышабыз. Гыйнвардан катнаш азык заводында экструдор цехы ачылды, ул төрле чималдан термик эшкәртү ярдәмендә гранулллы катнаш азык ясый. Ит комбинаты җитәкчелеге безгә Голландиядән 13 тонна минераль өстәмәләр кайтартты. Составында 58 микроэлемент булган бу өстәмә безгә гади бөртек катнашмасын да туклыклылык ягыннан кыйммәтле катнаш азык дәрәҗәсенә җиткерергә мөмкинлек бирә.

Узган җәйдә үзебездә 80 башка җәйге лагерь ясаган идек. Быел майдан дуңгызларны лагерьга чыгарып, үзебездә үрчем алырга җыенабыз. Җәйге лагерь «Рассвет»та бар, Синдряков исемендәге, «1 нче май»да төзеләчәк, аның файдасы беркемдә бәхәс уятмый инде хәзер. Шулай акрынлап поставщикларның тулы ышанычын, алар белән эшлекле мөнәсәбәтне кайтарырга, табышка эшләргә омтылабыз. Ул, билгеле, эш барышында тагын үзгәрешләр, яңалыклар таләп итәр, бу табигый хәл. Әмма район җитәкчелегенең дуңгызчылыкка игътибарын тойган хәлдә, без аларны хәл итәрбез дип уйлыйбыз, әлеге сәясәтне дөрес аңлаган поставщикларыбыз да аңа битараф калмаслар, максатыбыз уртак бит - итле булу.

**Әңгәмәдәш - С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

## Россиянең хәрби даны көннәре

# 2 ФЕВРАЛЬ - СОВЕТ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ СТАЛИНГРАД ЯНЫНДА НЕМЕЦ - ФАШИСТ ГАСКӘРЛӘРЕН ТАР - МАР ИТҮ КӨНЕ (1943)

Идел һәм Дон елгалары арасындагы олы мәйданда ике йөз көн һәм төн дәһшәтле Сталинград сугышы тынмады. Үзенең кискенлеге һәм югалтулары ягыннан тарихта бу бөек көрәшкә тиңнәр юк иде әле.

Канлы көрәшләрдә 62 нче, 64 нче армия сугышчылары дошман һөҗүменә каршы торырга көч тапты, Сталинградны фашистлар кулына бирмичә генә калмады, аның һөҗүм итү пунктларын көчсезләндерде һәм соңында совет гаскәрләре баш группаларын тулысынча тар - мар иттеләр.

Совет Кораллы Көчләренең Сталинград янында фашист гаскәрләрен камау һәм тар - мар итү буенча стратегик һөҗүм операцияләре 1942 елның 19 ноябреннән 1943 елның 2 февраленә кадәр сузылды. Оператив - стратегик вазифаларына карап операцияләрне шартлы рәвештә өч зур этапка бүләргә мөмкин: камалыштан чыгу, дошманның фланг группировкаларын тар - мар итү һәм немец танк армияләренең 6 нчысын һәм 4 нченең бер өлешен камалышта калдыру, генерал Манштейнның камалышта калган группаны коткарырга тырышуын юкка чыгару һәм совет гаскәрләренең камалыштан тышкы фронтта контрһөҗүм оештыруы; фельдмаршал Паулюсның камаудагы группировкалары тулысынча тар - мар ителүе.

... 1942 елның томанлы 19 нчы ноябре таңында аяз көнне яшен яшнәгәндәй, искәрмәстән дошман позицияләренә җимергеч «Катюша» залплары һәм меңнәрчә артиллерия утлары ява башлады. Шул агымга ияреп, тәвәккәл рәвештә Көньяк - Көнбатыш фронты пехота һәм танк гаскәрләре дә кузгалды.

20 нче ноябрьдә Сталинград фронты гаскәрләре хәлиткеч һөҗүмгә күчтеләр. Һөҗүм көчле дә, уңышлы да барды.

Генерал Н.Ф.Ватутин җитәкчелегендәге Көньяк - Көнбатыш һәм генерал А.И.Еременко җитәкчелегендәге Сталинград фронтларының танк һәм механизированный берләшмәләре контрһөҗүмгә каршылык күрсәтеп бер - берсенә каршы омтылдылар. 23 нче ноябрьдә ике фронтның да алдынгы частьлары билгеләнгән районда очраштылар.

Көньяк - Көнбатыш, Сталинград һәм Дон фронтлары гаскәрләре 330 кешелек 22 дивизия һәм 6 нчы һәм 4 нче танк армияләренең 160тан артык аерым частена кергән һөҗүм боҗрасын япты.

Верховный Башкомандование Ставкасы камалышта калган дошман гаскәрләренә соңгы һөҗүмне генерал К.К.Рокоссовский җитәкчелегендәге Дон фронтына тапшыра. Алар дошман көчләрен берничә өлешкә бүлеп һәркайсын аерым - аерым тар - мар итәргә планлаштыралар.

Камаудагы командованиегә капитуляция ясарга тәкъдим ителә. Тик дошман капитуляция өчен тәкъдим ителгән кешелекле шартларны кире кага. Шуңа күрә 1943 елның 10 нчы гыйнварында камалыштагыларга җимергеч артиллерия уты, авиабомбалар, совет пехоталары һәм танкларының көчле һөҗүме юнәлдерелә. Дошман җиңелүгә дучар ителсә дә, каршылык күрсәтә. Ләкин алга таба да каршы торуның мәгънәсезлеген аңлап фашист гаскәрләренең аерым подразделениеләре бирелә башлыйлар. 6 нчы армия фельдмаршалы Паулюс та шул исәпкә керә.

Операция 1943 елның 2 февраленда төгәлләнә. Иделдәге Җиңү Бөек Ватан сугышы барышында тамырдан борылыш ясады.

**И.САНДЛЕР.**

**(1941 - 1945 елгы Бөек Ватан сугышы тарихы материаллары буенча).**

*Тормыш шәхесләрен барлый*

# АВЫЛЫБЫЗНЫҢ ТАГЫН БЕР ГОРУРЛЫГЫ

**С**үз XX гасыр башларында татар милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, язучы, юрист Гаяз Исхакыйның дусты һәм көрәштәше булган Фуад Фәссах улы Туктаров турында бара.

Гаҗәеп күпкырлы талантка ия бу шәхеснең тормышы һәм эшчәнлеге ничә дистә еллар буена тарихи хезмәтләрдә булсын, әдәбиятта булсын, һаман да кара тамга белән тамгаланып килде.

Г.Исхакый белән чит илгә чыгып китүләре сәбәпле, аларны сатлык җаннар, шпионнар дип атаганнар. Соңгы елларда гына Фуад Туктаров шәхесе турында чын дөреслек мәгълүм булды. Ул татарның күренекле улы, татарның үз иле, үз теле булсын өчен гомере буена көрәшкән.

Фуад Фәссах улы Туктаров 1880 елның 5 февралендә Чистай өязенең Колбай Мораса авылында укымышлы гына галим Фәссах хаҗи гаиләсендә дөньяга килә. Әнисе Мәфтуха Чистайның мәшһүр һәм алдынгы карашлы сәүдәгәрләре Бадамшиннар кызы.

Фуад зиһенле бала булып үсә. 1901 елны ул Чистай мәдрәсәсеннән шактый төпле белем алып чыга. Укуын Казандагы татар укытучылар әзерләү мәктәбендә дәвам итә. Бу мәктәптә татар тарихында күренекле урын тоткан шәхесләр - М.Солтангалиев, С.Максуди, Г.Исхакый, Х.Ямашев, Ш.Мөхәммәдьяров, Тереговловлар, Акчуриннар һәм башкалар укып чыга.

Ф.Туктаров мәктәптә уку елларында Г.Исхакый белән дуслаша. Милли азатлык өчен көрәштә озак еллар бергә эшлиләр. Аларның фикерләүләре, дөньяга карашлары тәңгәл килә. Мәктәптә милли «Шәкертлек» түгәрәге оештырыла. Аның яшерен гәзите «Тәрәккый» чыгарыла. Фуад Туктаров түгәрәкнең актив әгъзасына әйләнә. Г.Исхакый мәктәпне бетереп киткәч, түгәрәкнең җитәкчесе булып кала. Иптәшләре арасында иң эшлекле, иң ышанычлылардан санала, урысча яхшы белә. Г.Исхакый искә алганча, бик динле булуы, бер намазны да калдырмыйча, уразаны бер дә бозмыйча тотып килүе белән аерылып тора.

Туганнары Фуадны мулла булыр, әтисе урынына кайтыр дип көтәләр. Ләкин ул башка юл сайлый. Шуңа туганнары матди ярдәм күрсәтмиләр, ул бик фәкыйрь яши, тамагын хосусый дәресләр биреп туйдырырга мәҗбүр була.

1905 ел вакыйгалары Фуад язмышында текә борылыш ясый. Ул баштанаяк сәясәт дөньясына чума, торган саен тирәнрәк итеп милли азатлык хәрәкәтенең эченә үтеп керә. Әлеге эшчәнлекнең бер нәтиҗәсе буларак, Ф.Туктарый 1905 елның августында мөселманнарның «Густав - Струве» пароходында үткәрелгән беренче съездларында катнаша. 1905 елның октябрендә «Шәһәр коммунасы» дигән штабны саклаучы милиционерлар сафында була һәм кулга алына. Иреккә чыгуга үз шөгыленә кайта.

Яшәеш һәм көрәш дәверендә Г.Исхакый белән милли азатлык өчен көрәшүне күздә тоткан берничә гәзит һәм журналлар чыгаралар: «Таң», «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы», «Дума», «Ил» һәм башкалар.

Бу гәзит - журнал битләрендә Фуад Туктарый берсеннән - берсе «усал», «тешләк» материаллар бастыра. Аның мәкаләләре «Усал» имзасы белән чыгарыла. Аның көн кадагына суга торган «Биш көн яткач», «Татар гәзитләре», «Татарлар тәракъкый итә» һәм башка мәкаләләрендә милли - мәдәни яссылыктагы мәсьәләләр күтәрелә.

Кискен сәяси юнәлеш өчен күп номер гәзитләр конфискацияләнә, кайбер гәзитләр ябыла.

Жандармерия кәгазьләрендә теркәлгәнчә, аның фатирында тентүләр үткәрелә. Кулга алына. Тентү нәтиҗәсез булу сәбәпле, иреккә чыгарыла.

Яшен ташы шикелле ялкынлы, хәрәкәтчән Мәхмүд - Фуад гәзиттәге эшчәнлеге белән генә чикләнми, әлбәттә. II Дәүләт Думасына сайлау көннәрендә (1907 ел) ул дусты Г.Исхакый белән бергә Чистай өязеннән кандидатурасын күрсәтүгә ирешә. Волость сайлауларында үтсә дә, хакимиятнең мәкерлеге аркасында төшеп кала. Думага уза алмый. Г.Исхакый аны Петербургка җибәрә. Дума каршында Туктарый ярдәме белән «Мөселман хезмәт таифәсе» төзелә, «Дума» дигән гәзитә чыгарыла. Бирелә дә милли мәсьәләләр күтәрелгән «усал» мәкаләләрен бастыра Туктарый. Фуадның тиктормас җан, актив җәмәгать эшлеклесе, революционер - көрәшче булуы бәхәссез.

Колбай Мораса егетенең мәкаләләре, әче чыгышлары, тәрҗемәләре 1906 - 1907 елларда Х.Ямашев җитәкләгән «Урал» (Оренбург), Г.Тукайның якыннан катнашы белән чыккан «Фикер», «Әлгасрелҗәдид» (Уральск) гәзит - журналлары битләрендә дә күренә.

1911 елда Казан университетының юридик факультетына укырга керә. 31 яшендә, күренекле шәхес, җитди сәясәтче. Ни өчен тагын уку? Көрәшчегә юридик законнарны тирәнтен белүенең мөһимлеген аңлый ул.

**Г.САДРЕТДИНОВА,**
**Колбай Мораса авылы Г.Кариев исемендәге музей директоры.**

**(Ахыры бар).**

# БӘЛЗӘМЛӘНГӘН СТАЛИННЫҢ МАВЗОЛЕЙДАН ЧЫГАСЫ КИЛМӘГӘН

**Б**өтен заман һәм халыкларның олуг атасы Иосиф Сталинның Мавзолейдан чыгарылып Кремль диварлары янында җиргә тапшырылуына да 35 елдан артык вакыт узып китте. Моңа карата шул чор матбугатында кыска гына хәбәрләр бирелгән. Ләкин юлбашчының яңа җеназасы шактый хәвефле шартларда уздырылган.

Кызганычка каршы, ул җеназада катнашучыларның күбесе вафатинде. Исәннәрдән берсе - Мәскәү Кремлен саклаган махсус полк солдаты Владимир Поршнев башкала үзәгендәге кайбер дулкынлануларны болай искә ала.

«Грузиннар әлеге хәлне ишетүгә Кызыл мәйданга җыелып митинг үткәрделәр. Пардашым Женя Яшин белән мавзолей янында тора идек. Смена килде. Чык та чык атлап кайту юлына чыктык. Кинәт грузиннарның йөгереп килүе күренде. « Юк, Сталинны чыгартмыйбыз! Чыгарырга ирек бирмәбез!» Аларның берсе Яшинның карабинына килеп ябышты. Аны тартып алмакчы була. Разводящий кушуы буенча мылтыкларны грузиннарга төбибез «Туктагыз, югыйсә атабыз!» Алар артка чөйкәлеп киттеләр. Арада грузиннар киеменнән яшерен сакчыларыбыз бар иде. Алар грузиннарны җиргә ятырырга керештеләр. Ул да түгел, Спас капкасыннан машиналар килеп чыкты, һәммәсен дә шуларга төядек. Ун минут эчендә мәйданны чистартып бетердек.

Әүвәлге солдат сүзләренә караганда, Сталинны 22 сәгать 50 минутта алып чыгалар. Поршнев хезмәт иткән ротага командир кереп: « Ике-өч ел хезмәт итүчеләрдән ун кеше минем янга! - дип боерык бирә. - Коралларны калдырырга. Табуты белән Сталинны күтәреп чыгарга ярдәм итәргә кирәк». Табутны илтүе бик авыр, чөнки аның бер каты кургашын иде...

Юлбашчыны соңгы юлга илткәндә хәрбиләр һәм партия эшлекләреннән башка мавзолей лабораториясе хезмәткәрләре дә бар. Алар, әлбәттә, мәетләрне бәлзәмләү белән шөгыльләнүчеләр иде. Шулардан берсе - ни өчен икәнен үзе дә белмичә, - төнгә каршы мавзолейда калдырылган булган. Менә бервакыт КПСС ҮК каршындагы партконтроль комитеты рәисе, КПСС ҮК президиумы әгъзасы Николай Шверник килеп төшеп мәетнең чыгарыласын белдерә. Залда табут пәйда була. Ул чимә-чи тактадан ясалган. Хәрбиләр Сталин гәүдәсен мәет ятагына урнаштыралар һәм аны алып чыгалар. Алдан ук көтелгәнчә Кремль дивары янында чокыр әзер булганлыктан, күмү эшләрен бик тиз төгәллиләр. Сүз уңаеннан әйтсәк, әлеге җеназага шаһит булучылар сүзенә караганда кич ул көнне галәмәт шыксыз була, яңгыр чиләкләп коя.

Бая искә алынган лаборатория белгечләреннән берсе, үзенең исемен белгертмәүне теләгән хезмәткәр:

-Әгәр бүген Иосиф Виссарионовичның каберен ачып карасак, бик яхшы бәлзәмләнгән булса да, тәненнән берни дә калмаганлыгын күрербез, - ди.

Ленинның тәнен бәлзәмләүдән аермалы буларак, Сталинны бөтенләй башка ысул белән бәлзәмләгәннәр. Бу ысулны даһи совет галиме академик Мардашев уйлап тапкан ( ул 74 нче елда вафат була). Сталин җеназасын яңадан үткәрү кебек үк, аны бәлзәмләү дә үтә яшерен шартларда уздырыла. Мардашев сер сыярлык бик якын хезмәттәшенә беркөнне өенә кайтып китмичә тоткарланып торырга, бәлзәм матдәләрен хәзерләргә куша. Фәкать төн уртасында гына ул бөек Сталинның мәетен гасырлар дәвамына мәңгеләштерергә кирәк икәнлеген абайлап ала. Лабораториягә шулай ук 4 нче идарәдән табиблартөркеме килә. Алар мәетне ярып медицина таныгын язалар, аннары аны кулдан-кулга бәлзәмчеләргә тапшыралар. Ул төндә вакытлы бәлзәмләү генә үткәрелә, янәсе, халык юлбашчы белән саубуллашканда тегенди-мондый таркалу исен сизмәсен. Ә чын бәлзәмләү ел буена дәвам иттерелә. Әлеге ысулның хикмәте тәндәге суны бүтән сыеклыклар белән алыштыруда була. Биология химиясе белгече Мардашев тәннең барлык физиологик төзелешен сакларга омтыла. Моның өчен тәнне махсус сыеклыклар белән туендыралар.

Югарыда искә алынган әңгәмәдәш әлеге сүзен җөпләп:

-Әгәр табут чынлап та чи такталардан ясалса, Сталин мәете шундук таркала башлаган булырга тиеш,- ди. -Ә инде җир асты дымы, кар сулары һәм яңгырлар бөтен эшне төгәлләп куя.

Соңыннан Мардашев ысулы белән җитәкчелекнең бүтән әһелләре дә бәлзәмләнә. Ә нәтиҗәләре көтелгәнгә караганда да бик күпкә артыграк була.

60 нчы елларда Сталин мәетен мавзолейдан чыгару бик күпләрне тетрәндергән, хәтта бу вакыйга меңнәрчә гаиләләрнең бәхәсләшеп китеп, таркалуына сәбәп булса да, бүгенге көндә халыкның хәле үле юлбашчылар турында кайгырырлык кынамыни...

**(«Московский комсомолец» газетасыннан).**

# ГАЗ ШАРТЛЫЙ ДА ӘЛЕ УЛ

***Соңгы өч елда районда көнкүрештә газдан файдалану куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә шәхси секторда дүрт күңелсез вакыйга килеп чыкты, корбаннар да булды.***

Өендә газ приборлары булган кешеләр газга бәйле әйберләрне алыштыру һәм ремонтлау сыйфаты өчен җаваплылык шәһәр газ хуҗалыгы белгечләре өстендә икәнлеген белергә тиешләр. Ә менә торак биналарда газ приборларыннан куркынычсыз файдалану өчен җаваплылык тулысынча йорт яки фатир хуҗаларында, ягъни абонентлар җилкәсендә. Һәм бу һич тә буш сүз генә түгел, әгәр газ приборлары белән үзбашка эш итү аркасында бүтән кешеләргә дә зыян килгән очракта җинаять җаваплылыгы да кузгатыла. Андый очракларда иминият (страховка) түләнми. Газ системасында нинди генә төзексезлек сизелсә дә, андый чакта гадәттә газ исе чыга, кичекмәстән 04 телефоны белән хәбәр итәргә кирәк.

Караңгы бүлмәдә газ исе сизеп кешенең үзеннән үз... электр өзгечкә сузылу очраклары еш булып тора. Нәк... менә шул чакта электрүткәргечләр арасындагы контакттагы очкыннан шартлау килеп чыга да инде. Газ буенча белгечләр килгәнгә кадәр бүлмәне җилләтергә кирәк. Бу уңайдан челтәр газының һавадан җиңелрәк булуын һәм андый очракта тәрәзәне яки форточканы ачу да җитүен, ә менә баллонлы газ һавадан авыррак булганга күрә аны форточка ачып кына чыгарып бетерү мөмкин түгеллеген онытырга ярамый.

Хәзер газ баллоннарының төрле зурлыктагысы бар. Бу очракта еш кына баллоннарның сыйфатын, аларның тулы булу булмавын ачыклавы мөмкин дә булмый. Шуңа күрә газлы баллоннарны үлчәп карау мөмкинлеге булган һәм сезгә бирелә торган баллонның төзеклеге гарантияләнә торган махсус станцияләрдән генә сатып алырга кирәк.

## *Танышырга телим*



Гаилә кору өчен хатыны үлгән 50 - 58 яшьлек ышанычлы, намуслы һәм интеллигент мөселман ир - ат белән танышырга телим. Хәмер белән мавыгучылар, хөкем ителгәннәрнең борчымавын сорыйм. Үземә 55яшь, буем 162см. Телефон аша хәбәрләшү очрашуны тизләтер иде,булмаса үз адресыгызны язып конверт җибәрсәгез дә ярый. Хатларны Норлатка үзәк элемтә бүлегенә I- АР 715472 паспорт иясенә адреслап җибәрергә.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, җомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 1620 данә. **Заказ N 5149.**